РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

11 апрель, 2025 ел Кукмара ш. № 303

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 85 номерлы карары белән раслаган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә Муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә кертелә торган кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 95 номерлы, 2022 елның 24 августындагы 141 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 195 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 226 номерлы һәм 2024 елның 29 мартындагы 242 номерлы карарлары редакциясендә) расларга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның «11» апрелендәге 303 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

1. 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Гадәттән тыш югары хәвеф һәм югары хәвеф категорияләренә кертелгән контроль объектлары булмау сәбәпле, мәҗбүри профилактик визитлар уздыруның ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

2. 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда, Контроль органы тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта, муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда, әгәр контроль төре турында Федераль законда, муниципаль контроль төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Гомуми таләпләрдә башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәге профилактик чараларны үткәрү мәҗбүри була:

- мәгълүмат җиткерү;
- кисәтүләр игълан итү;
- консультация бирү;
- профилактик визит.»;

3. 3.11 пунктның дүртенче абзацында «, контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган яисә китерергә мөмкин булган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә барлыкка килгән зыяннарны бетерү сроклары» сүзләрен өстәргә»;

4. 3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Профилактик визит Контроль органы тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган рәвешләрдә һәм тәртиптә үткәрелә.

248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Контроль органы тарафыннан мәҗбүри профилактик визит үткәрелә. Контроль орган, күрсәтелгән Федераль законда каралган нигезләр булганда, тиешле актлар төзи, контрольдә тотылучы затка карата мәҗбүри профилактик визитны кабат уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында контрольдә тотылучы затка күрсәтмә бирә.

248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, Контроль органы контрольдә тотылучы зат башлангычы белән профилактик визит үткәрергә мөмкин.»;

5. 4.20 пунктта:

- беренче абзацта «аңлатулар» сүзен «язма аңлатмалар» сүзләренә алмаштырырга;

- икенче абзацта «аңлатулар» сүзен «язма аңлатмалар» сүзләренә алмаштырырга;

6. 4.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.21. Документлар буенча тикшерү үткәрү срогы 248-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән көннәр санынннан арта алмый. Күрсәтелгән срокны исәпләү 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә торган чорга туктатыла.»;

7. 4.22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.22. Планнан тыш документлар буенча тикшерү, 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

8. 4.25 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.25. Планнан тыш күчмә тикшерү, 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

9. 4.27 пунктта:

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча, контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.»;

- дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән очракта.»;

10. 4.29 пунктының икенче һәм өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль чараны үткәрү барышында Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган җирләрдән файдалануга һәм аларны саклауга карата мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, контроль чара актында мондый хокук бозу турында 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәгълүмат күрсәтелә. Контроль органының вазыйфаи затлары дәүләт җир күзәтчелеге органына муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль чарасын уздыру нәтиҗәсендә төзелгән, контрольдә тотылучы зат белән берлектә уздырылган күрсәтелгән актның күчермәсен җибәрәләр. Контроль органы җирләрдән файдалануга һәм саклауга карата мәҗбүри таләпләрне, шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә мөмкин.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль чарасын үткәрү барышында Россия Федерациясе субъекты законнарында административ җаваплылык каралган җир мөнәсәбәтләре объектларына карата җирләрдән файдалануга һәм аларны саклауга карата мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган бозу өчен җаваплылыкка тарту РФ ЗК, Административ хокук

бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла..»;

11. 4.31 пунктта:

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контроль чара акты үзара хезмәттәшлектән башка төзелгән очракта һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка очракларда Контроль органы актны контрольдә тотылучы затка күрсәтелгән Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.»;

- бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

12. Түбәндәге эчтәлекле 4.36 пунктын өстәргә:

«4.36. 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда һәм тәртиптә Контроль органы тарафыннан контрольдә тотыла торган затка ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелә.

248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда һәм тәртиптә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны тиешенчә бетерү турында килешү төзелергә мөмкин.»;

13.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Аларның фикеренчә, хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре муниципаль җир контроле кысаларында турыдан-туры бозылган контрольдә тотыла торган затлар түбәндәгеләргә карата 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган карарларга, актларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.»;

14. 7.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.12. Шикаять шикаятьне карауга вәкаләтле орган тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вакыт эчендә каралырга тиеш.».